*Бу хикәяне Турай авылында туып үскән, Бәзәкә мәктәбендә һәм Казан дәүләт институтында укып, бүгенге көндә Кукмара районындагы Олы Сәрдек авылында яшәп эшләүче Гөлия Хисаметдинова (Мөхәмәтгәрәева) ире Харисның туган яклары турында язган. Безнең якларда 20 гасыр дәвамында Кукмараның балта осталары, итек басучылары, шәл бәйләүчеләре ел саен була торган иде. Шунысы да кызыклы, Бәзәкә авылы зиратында 1827 елда вафат булган Олы Сәрдек авылы кешесе Гатиатулла бине (улы) Ишмөхәммәд күмелгән- бу турыда кәбер ташындагы язу бар (карагыз: "История. Бәзәкә зираты ташлары, пункт 15"). Нинди ерак аралар булуга карамастан безнең эби-бабаларыбыз аралашып, туган якларыннын күченеп тә яшәгәннәр.*

Исәнмесез, хөрмәтле "Бәзәкә" сайты кунаклары, кадерле якташлар! Хисләремне йөгәнли алмаган вакытларда,минем аларны кәгазьгә ышанып тапшыра торган гадәтем бар, ул бит барысына да түзә. Иремнең туган якларына барып кайтканнан соң язылган бу язмамны сезгә дә юлларга булдым. Ул руслар яши торган җирдә туган, татарча аралаша белсә дә, күңелдәгеләрен минем кебек үк әйтә алмас кебек тоелды да, мин аның исеменнән яздым. "Муж и жена- одна сатана", дип белмичә әйтмәгәннәр икән. Яши- яши без дә бер- беребезне сүзсез дә аңларга өйрәндек. Үзем дә туган якларымнан ераграк яшәгәнгә күрәдер, мин аның халәтен ачык сиздем. Гаеп итмәссез дип өметләнәм. Бу язма "Күңелдәге төер" исеме астында "Ватаным Татарстан" газетасы битләрендә дә басылган иде. Тик корректорларның "исәйгәч" дигән сүземне "ишәйгәч"кә алыштырганнарын күргәч кәефем генә киткән иде.

Турай кызы, Гөлия Мухаметгареева (Хисамутдинова)

# Ямьле булса да торган җир...

Кеше кайда гына яшәсә дә кендек каны тамган, тәүге аяк баскан туган җирен гомере буе сагынып яши икән. Мин дә шундыйларның берсе. Минем әти, Хисаметдинов Галәүтдин, Арча районы Миржәм авылында 1906 елда туган. Кечкенәдән әтисез калып, тормышның әчесен күп татыган ул. Бөек Ватан сугышы ветераны, Берлинны азат итүдә катнашкан. Сугышчан 3 дәрәҗә Дан ордены, Кызыл Йолдыз ордены; "За взятие Берлина", "За победу над Германией" һәм башка күп санлы юбилей медальләре белән бүләкләнгән. Әни, Йөзмөхәммәтова Әнвәрбикә, Кукмара районы Зур Сәрдек авылы кызы. Әни назын бөтенләй күрмәгән бала, үги әни касәсеннән туйганчы эчкәндер ул. Сугыш беткәч ихтыярый- мәҗбүри торф чыгару эшенә җибәрелгән яшьләрнең берсе. Киров өлкәсе Кирово- Чепецк

шәһәренә якын гына урнашкан Каринторф бистәсендә очрашып кавышканнар алар.1960 елның апрелендә мин - аларның бердәнбер балалары дөньяга килгәнмен.

Без үз йортыбыз белән урман эчендә урнашкан 3нче дип аталган бистәдә яшәдек. Мин 6 нчы классны тәмамлагач, эти белән әни, минем киләчәгемне уйлаптыр, әнинең туган ягы Кукмара районы Зур Сәрдек авылына кайтып төпләнәләр. Мин- алты ел рус мәктәбендә укыган бала, 7 нче класска татар мәктәбенә укырга килдем. Әдәбият дәресендә татарча шигырь сөйләгәч, кычкырып көлделәр. Шулай итеп мин урта мәктәпне рус телендә тәмамладым. Укытучыларым, рәхмәт, хәлемә керделәр: аңламаган материалны рус телендә аңлатып, рус телендә биргән җавапларымны кабул итәләр иде. Күп еллар үткәч кенә мин татарча аралаша башладым. Мәктәптән соң институт тәмамладым, гаилә корып җибәрдем , улым белән кызым туды.

Балалар бераз исәйгәч, гаиләмне үземнең туган якларымны күрсәтергә алып киттем. Аяк астында шундый чиста, йомшак ком күрмәгән балалар комда уйнап кинәнделәр. Нарат урманының ылыс исеннән башлар әйләнерлек. Мин туган бистә яши. Күрше-күләннәрнең хәлен белдек, бергә уйнап үскән яшьтәшләрне дә танып була әле.

Шушы барудан соң туган якларга шактый еллар барып чыгарга җай булмады: йорт җиткерәсе, балалар укытасы, әнинең кинәт кенә, көтмәгәндә вафатыннан соң этине тәрбиялисе. Ул 90 яшен тутырып арабыздан китте. Ә туган төбәгем күңелдән чыкмады. Ә бер көнне, уйлаштык та, тиз генә җыенып поезд белән Киров якларына юл алдык. Берәр таныш очрамый калмас әле, дидек. Юл шактый озын, әмма күзгә йокы кермәде. Менә мин башка бер җирдә дә күрмәгән таныш ике катлы агач йортлар, мәгърур наратлар. Просница станциясендә төштек тә, Чепецкка баручы автобуска утырдык. Узкоколейкада поезд көтеп торабыз. Бездән ерак түгел генә 2 ир-ат сөйләшәләр. Берсенең тавышы таныш кебек тоелды, борылып карасам – Рифат. Ул да мине таныды. Тиз генә энесенә шалтыратты. Бераздан минем дустым-сабакташым Фәргат тә килеп җитте. Өйләренә алып кайтып кунак итте. Рус кызына өйләнгән икән, хатыны аңа Федор дип, я Федя дип дәшә. Гөлия Фәргат дип эндәшеп караган иде дә, ул исем аңа ят кебек тоелды бугай дип уйладык.

Безне тетрәндергән, үзәкләрне өзгән хәбәр: мин дөньяга килгән, бала чагымны уздырган бистә юк инде. Кеше яшәсен өчен өч фактор кирәк дип уйлыйм мин- ипи, су, юл. Узкоколейканы сүткәннәр, утны өзгәннәр, анда яшәп ятучы карт-корыга ипи китерүдән туктаганнар. Үзәк бистәдәге бер торакны картлар йорты итеп, исәннәрне шунда күчереп куйганнар.

Келтер- келтер килеп 4-5 вагонын таккан тепловоз безне Үзәк бистәгә алып килде.Ул елны бакча җиләге ишеп уңган иде, вагонга җиләк тулы кәрҗиннәрен тотып апа- әбиләр тулды. Җиләк исеннән авызга сулар килде.Әнинең ахирәте Тәскирә апа, аның Тәслимә исемле кызы бар иде, шуларны эзләп киттек. Монда кеше берсен- берсе белә, адресларын әйтеп, юлны өйрәтеп җибәрделәр. Беренче карашка бернинди дә үзгәреш юк. Шул

ук йортлар, шул ук яланаяк йөрисе килгән ком, шул ук наратлар. Тик кибет тирәсендә, ашханә янында көпә-көндез салмыш ир-атлар, сыра шешәсе тоткан хатын-кыз күзгә чалына.

Тәслимәне (аны монда Таня яисә Тася дип йөртәләр) тиз таптык. Чәйләп алгач, без Тәскирә апаны күрергә киттек. "Харис что-ли приехал?" - дигән тавышка "дерт" итеп куйдык. Күтәрелеп карасак, икенче катның бер тәрәзәсеннән баш күренә. Ул арада Соня безнең янга төшеп тә җитте. Хәл-әхвәл сорашкач, таныш-белешләрне барларга керештек. Безнең күршеләребезнең кайсы туган ягына кайтып киткән, кайсы якты дөньядан мәңгелек йортка күчкән.

Үзәк бистәдә халык авыр яши. Эш табуы кыен. Кем Кирово-Чепецк шәһәренә барып эшләп йөри, кем җәен - көзен җиләк, гөмбә җыеп сата, кем әнисенең пенсия акчасына яши. Юньле тормыш күрергә ышанычы беткәне эчүгә сабыша. Кибетләр бездәге кебек үк бай, ләкин акча ягы сай. Аларның яшәешен, көнкүрешен карап, без әти белән әнигә мең кат рәхмәт укыдык. Туганнарсыз, әти-әнисез (алар өлкән яшьтә иде инде), ялгызым нишләр идем? Бергә уйнап үскән дусларымның кайсы төрмә юлын таптаган, бик күбесе күптән мәрхүм. Мул, тыныч тормышта яшәүчеләрен бармак белән санарлык.

Бу кадәр юл килгәч, үзем үскән нигезне күрми китәсе килмәде. Икенче көнне аякларга резин итекләр кидек тә, җәяүләп 3нче бистәгә киттек. Соня алдан, арта Гөлия бара. Ап- ак ком өстендә елан эзләре. Ялгыш басмыйк дип, карап кына барабыз. Шпалалар алынган, күренер- күренмәс тимер юл эзеннән атлыйбыз. Менә, ниһаять, бистә, менә безнең урам, менә безнең нигез. Аны инде куаклар басып киткән диярлек, якынрак килергә куркыныч. Ике катлы йортлар, кайчандыр күп еллар элек пленда булган немецлар төзегән таш мунча, мәктәп үз урыннарында. Бистә бөтенләй үк үлмәгән икән: үз йортлары белән яшәүче берничә кеше бар. Туган җиреннән аерылган, үскән нигезен югалткан кеше халәте күз алдына килеп басты. Минем арттан елый- елый, күз яшьләрен сөртеп Гөлия атлый. Мине кызганамы, әллә беренче тапкыр килгәндә шаулап- гөрләп яшәп яткан бистә һәм аның халкынмы? Без күңелсез, авыр уйлар белән кайттык.

Тәскирә апа белән сөйләшәбез. Ул да гомеренең көзен үтеп бара. Татар зияраты бармы, дип сорадык. Юк икән. Татарны да, русны да, башка милләт кешеләрен дә бер зияратка русча күмәләр икән. Мин күлмәк, башка кирәк- яракларны әзерләп куйдым инде, ди.

Без хәзер Киров якларына ел саен барабыз. Минем укытучым Спирина Валентина Ивановнаны күрәсем килә иде. Эзләп таптык, хәлен белеп, алып килгән күчтәнәчләребезне биреп сөендердек. Аның яныннан чыгып килгәндә почтальон сумкасы аскан берәү белән йөзгә- йөз очраштык. Бу бит Даша (мулла кушкан исеме Гөлдәрья), безнең әти-әниләр дуслар булып аралашып яшәделәр. Ире Вова белән матур гына яшәп яталар. Без килгәндә, бөтен эшләрен ташлап, безнең күңелне күрәләр. Искиткеч тәмле уха пешерәләр, балык кыздыралар. Вова үзе сунарчы, үзе

балыкчы. Балыкның ниндие  генә юк аларда! Ә мунчага нинди генә вениклар әзерләми алар. Бик эшчән, тырыш кешеләр,исең китәрлек. Иң элек Вова безне 3нче бистәгә алып бара. Мәктәп белән мунча әле дә торалар. Тик йортларның калай түбәләрен инде сүтә башлаганнар, “бизнес”- металлоломга тапшырып акча ясыйлар. “Без асфальт балалары бит”, дип үзебездән көлә- көлә, куркып булса да, урманга барабыз. Без кара җиләк, Вова гөмбә җыя. Анда гөмбә дә бүтән төрле тәмле.  Бераз соңрак барсак, брусника да тәмләп карарга өлгерәбез.  Урман, елга барында кешегә яшәргә мөмкинлек бар икән бит, дигән уй килә башка.Зияратка барып таныш- белеш, күрше- күлән, сабакташларның каберләрен эзлибез. Белгән догаларыбызны укып чыгабыз. Аларның зиураты безнеке кебек түгел: урман эчендә, бүлеп тә алынмаган. Бер чардуган эчендә берничә буын туганнар ята. Һәм иң күңелгә ятышлысы- андагы тәртип- чисталык. Кайберәүләргә алардан үрнәк алырлык. Безнең зиуратларда каралмаган, чүп баскан каберләр очрый. Йөрәкне әрнеткәне- аларның бит авылда балалары, туганнары бар.

Соңгы елларда Үзәк бистәдә зур үзгәрешләр бара. Иске йортлар экренләп сүтелә, 2 катлы заманча йортлар төзиләр. Шулай да безне сөендергән мәсьәлә башка. Даша, көченнән килгәнчә, мөселман дине белән кызыксына. Алар ел саен диярлек җыелышып автобус белән Болгарга сәфәр кылалар. Вова милләте белән мордва. Бер кызлары христиан динен, икенчесе мөселман динен якын итә. Бер бүлмәләрендә Корьәннән сүрәләр эленгән. Алар берсен- берсе хөрмәт итеп, дус- тату яшиләр, милләт- дин төрлелеге аларга комачауламый. Даша татарча җырларга ярата. Без анда тагын бер Харисны таптык. Ул бик матур итеп гармунда уйный. Ике Харис чиратлашып гармунда уйныйбыз, Даша белән Гөлия җырлыйлар. Без алар янында елга җитәрлек энергия җыеп кайтабыз. Бистә яшәсә, анда Владимир, Гөлдәрья, Харис кебек киң күңелле, туган җанлы кешеләр исән булса, мине туган ягым, туган туфрагым белән бәйләгән җепләр өзелмәс дигән өмет яши.

Харис Хисаметдинов,<br>Кукмара районы Зур Сәрдек авылы



Вагон эче. Тар гына агач
утыргычлар. Кышкы суыкларда
ягар өче пиче дә бар


Үзәк бистәдән
Каринкага йөри
торган паровозик.
2004 ел





Харис дусты, сабакташы Фәргат- Федя белән Чепца елгасы буенда



Туган як кырлары буйлап сәяхәттә. Менә алар- киң күңелле, ачык йөзле дусларыбыз- Вова һәм Даша



Пленда булган немецлар төзегән мәктәп бинасы. 2004 ел



Харис поездан төшкәч. Бераз ямансу. 2002 ел



Харисның туган нигезе.
Шомырт агачыннан 2 метр
сулдарак



Энче бистәгә бара торган
узколейка